**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**КАРАР**

2020 елның «12» октябреннән

№ 250

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында эшләүче, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы, югары квалификацияле спортчылар әзерләгән тренерларны, шулай ук спорт инструкторларын һәм спортчыларны спорт ярышларында алган нәтиҗәләре өчен бүләкләү турында Нигезләмәне раслау хакында»**

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерларны, шулай ук спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче спорт инструкторларын һәм спортчыларны бүләкләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү Тәртибен раслау турында» 2018 елның 29 декабрендәге 1258 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 22 октябрендәге 946 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты **карар бирә**:

1. Кушымта итеп куелган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында эшләүче, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы, югары квалификацияле спортчылар әзерләгән тренерларны, шулай ук спорт инструкторларын һәм спортчыларны спорт ярышларында алган нәтиҗәләре өчен бүләкләү турында» Нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә ел саен Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы белән «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында эшләүче, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы,

югары квалификацияле спортчылар әзерләгән тренерларны, шулай ук спорт инструкторларын һәм спортчыларны спорт ярышларында алган нәтиҗәләре өчен бүләкләү турында» Килешү төзүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар, 2020 елга (2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына) бюджетлардан башлап, Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары төзегәндә һәм үтәлгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), шулай ук Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru урнаштырырга.

5. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 2 июнендәге 135нче номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында эшләүче, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы, югары квалификацияле спортчылар әзерләгән тренерларны, шулай ук спорт инструкторларын һәм спортчыларны спорт ярышларында алган нәтиҗәләре өчен бүләкләү турында Нигезләмәне раслау хакында"гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе**
**вазифаларын башкаручы** **В.Н. Семеняк**

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә
муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның «12» октябрендәге № 250
карары белән расланган

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында эшләүче, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы, югары квалификацияле спортчылар әзерләгән тренерларны, шулай ук спорт инструкторларын һәм спортчыларны спорт ярышларында алган нәтиҗәләре өчен бүләкләү турында
Нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә, югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерларны, шулай ук спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында эшләүче, спорт ярышларында алган нәтиҗәләре өчен спорт инструкторларын, спортчыларны бүләкләүне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслау максатларында, Татарстан Республикасы бюджетыннан Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар (алга таба- Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районына башка бюджетара трансфертлар) бирү кагыйдәләрен, максатларын һәм шартларын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә физик культура һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслау максатларында, югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерларны, шулай ук Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында эшләүче, спорт ярышларында алган нәтиҗәләре өчен спортчы инструкторларны һәм спортчыларны бүләкләү өчен бирелә.

3. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчаларын баш бүлүче- Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы (алга таба - Министрлык).

4. Башка бюджетара трансфертлар әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга тиешле финанс елына Министрлыкка җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

5. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районын башка бюджетара трансфертлар алу өчен сайлап алу критерияләре булып, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмасында түбәндәге күрсәткечләр булу тора:

алдагы календарь елда спорт әзерлеге үтүче затлар тарафыннан рәсми халыкара, бөтенроссия, төбәкара, республика ярышларында (Олимпия уеннарында, дөнья чемпионатларында, Дөнья кубокларында, Европа чемпионатларында, ир-атлар һәм хатын-кызлар арасында рәсми халыкара

ярышларда, Европа Кубокларында, Бөтендөнья Универсиадаларында, Россия чемпионатларында, Россия Кубокларында, федераль округ чемпионатларында, Татарстан Республикасы чемпионатларында, яшьләр һәм юниорлар арасында Россия беренчелекләрендә, Бөтенроссия Универсиадаларында, дөнья, Европа беренчелекләрендә, Бөтендөнья яшүсмерләр уеннарында, Европа яшүсмерләр фестивальләрендә, яшүсмерләр арасында, олырак үсмерләр арасындагы рәсми халыкара ярышларда, олырак үсмерләр арасындагы Россия беренчелекләрендә, Россия укучылары Спартакиадасы финалларында, Югары Россия Федерациясе Спорт министрлыгының бердәм календарь планына кертелгән Бөтенроссия ярышларында, Идел буе федераль округы беренчелекләрендә) югары нәтиҗәләргә ирешү;

спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары спортчылары-инструкторлары һәм спортчылары тарафыннан рәсми халыкара һәм бөтенроссия ярышларында (Олимпия уеннарында, дөнья чемпионатларында, дөнья кубокларында, Европа чемпионатларында, Европа Кубокларында, дөнья беренчелекләрендә, Бөтендөнья Универсиадаларында, Россия чемпионатларында, Европа беренчелекләрендә, Россия кубокларында, Россия беренчелекләрендә, Бөтенроссия Универсиадаларында) алдагы календарь ел эчендә югары нәтиҗәләргә ирешү.

Тренерлар, тренер-укытучылар хезмәтенә
адаптив физик культура буенча (шул исәптән өлкәннәр белән эшләү)
Бер шөгыльләнүче исәбенә
Ярышларда алган урын буенча
Югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен
түләү нормативлары
(процентларда)

| Ярышларның дәрәҗәсе | Алынган урын | Хезмәткә түләү нормативлары | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Спортның олимпия төрләре, олимпия дисциплиналары | | Спортның олимпия булмаган төрләре, олимпия булмаган дисциплиналары | |
| | | шәхси | команда | шәхси | команда |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| Олимпия уеннары | 1 | 500,0 | 500,0 | - | - |
| | 2 | 375,0 | 375,0 | - | - |
| | 3 | 250,0 | 250,0 | - | - |
| | 4 | 200,0 | 200,0 | - | - |
| | 5 | 188,0 | 188,0 | - | - |
| | 6 | 125,0 | 125,0 | - | - |
| | катнашу | 63,0 | 63,0 | - | - |
| Дөнья Чемпионаты | 1 | 75,0 | 75,0 | 52,5 | 37,5 |
| | 2 | 70,0 | 70,0 | 50,0 | 35,0 |
| | 3 | 65,0 | 65,0 | 47,5 | 32,5 |
| | 4 | 60,0 | 60,0 | 45,0 | 30,0 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 5 | 55,0 | 55,0 | 42,5 | 27,5 |
| | 6 | 50,0 | 50,0 | 35,0 | 25,0 |
| Дөнья Кубогы, Европа чемпионаты | 1 | 70,0 | 70,0 | 50,0 | 35,0 |
| | 2 | 65,0 | 65,0 | 45,0 | 32,5 |
| | 3 | 60,0 | 60,0 | 42,5 | 30,0 |
| | 4 | 55,0 | 55,0 | 37,5 | 27,5 |
| | 5 | 50,0 | 50,0 | 35,0 | 25,0 |
| | 6 | 45,0 | 45,0 | 32,5 | 22,5 |
| | 7 - 12 | 15,0 | 15,0 | 12,5 | 7,5 |
| Ир-атлар һәм хатын-кызлар арасында рәсми халыкара ярышлар | 1 | 20,0 | 20,0 | 10,0 | 10,0 |
| | 2 | 17,5 | 17,5 | 8,8 | 8,8 |
| | 3 | 15,0 | 15,0 | 2,5 | 7,5 |
| Европа Кубогы | 1 | 60,0 | 60,0 | 42,5 | 30,0 |
| | 2 | 55,0 | 55,0 | 37,5 | 27,5 |
| | 3 | 50,0 | 50,0 | 35,0 | 25,0 |
| | 4 | 45,0 | 45,0 | 32,5 | 22,5 |
| | 5 - 10 | 22,5 | 22,5 | 20,0 | 11,3 |
| Бөтендөнья универсиадасы | 1 | 45,0 | 45,0 | 32,5 | 22,5 |
| | 2 | 40,0 | 40,0 | 27,5 | 20,0 |
| | 3 | 35,0 | 35,0 | 22,5 | 17,5 |
| | 4 - 6 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 10,0 |
| Россия Чемпионатя | 1 | 50,0 | 17,5 | 35,0 | 8,8 |
| | 2 | 45,0 | 15,0 | 32,5 | 7,5 |
| | 3 | 40,0 | 12,5 | 27,5 | 6,3 |
| | 4 | 35,0 | 10,0 | 25,0 | 5,0 |
| Россия Кубогы | 1 | 40,0 | 15,0 | 27,5 | 7,5 |
| | 2 | 35,0 | 12,5 | 22,5 | 6,3 |
| | 3 | 30,0 | 10,0 | 20,0 | 5,0 |
| | 4 | 25,0 | 8,5 | - | 4,3 |
| федераль округ чемпионаты | 1 | 25,0 | 7,5 | 22,5 | 3,8 |
| | 2 | 20,0 | 7,0 | 18,0 | 3,5 |
| республика чемпионаты | 1 | 20,0 | 3,5 | 20,0 | 1,8 |
| Россия беренчелеге (яшьләр, үсмерләр) | 1 | 35,0 | 7,3 | 30,0 | 3,7 |
| | 2 | 30,0 | 6,8 | 25,0 | 3,4 |
| | 3 | 25,0 | 6,3 | 22,5 | 3,2 |
| | 4 | 20,0 | 5,8 | 20,0 | 2,9 |
| Бөтендөнья универсиадасы | 1 | 35,0 | 7,3 | 30,0 | 3,7 |
| | 2 | 30,0 | 6,8 | 25,0 | 3,4 |
| | 3 | 25,0 | 6,3 | 22,5 | 3,2 |
| | 4 | 20,0 | 5,8 | 20,0 | 2,9 |
| | 1 | 45,0 | 45,0 | 32,5 | 22,5 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Дөнья, Европа беренчелеге | 2 | 40,0 | 40,0 | 27,5 | 20,0 |
| | 3 | 35,0 | 35,0 | 22,5 | 17,5 |
| | 4 - 6 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 10,0 |
| Бөтендөнья яшүсмерләр уеннары | 1 | 45,0 | 45,0 | 32,5 | 22,5 |
| | 2 | 40,0 | 40,0 | 27,5 | 20,0 |
| | 3 | 35,0 | 35,0 | 22,5 | 17,5 |
| | 4 - 6 | 20,0 | 20,0 | 20,0 | 10,0 |
| Европа яшүсмерләр фестивале | 1 | 40,0 | 40,0 | 20,0 | 20,0 |
| | 2 | 35,0 | 35,0 | 17,5 | 17,5 |
| | 3 | 30,0 | 30,0 | 15,0 | 15,0 |
| | 4 - 6 | 20,0 | 20,0 | 10,0 | 10,0 |
| Яшүсмерләр, өлкән яшүсмерләр арасында рәсми халыкара ярышлар | 1 | 22,5 | 15,0 | 15,0 | 15,0 |
| | 2 | 20,0 | 12,5 | 12,5 | 12,5 |
| | 3 | 17,5 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| | 4 | 15,0 | 7,5 | 7,5 | 7,5 |
| Россия беренчелеге (өлкән егетләр) | 1 | 35,0 | 6,0 | 18,0 | 3,0 |
| | 2 | 28,0 | 5,5 | 14,0 | 2,7 |
| | 3 | 20,0 | 5,0 | 10,0 | 2,5 |
| Россия яшьләре Спартакиадасының финалы | 1 | 37,5 | 7,5 | 32,5 | 3,8 |
| | 2 | 32,5 | 7,0 | 27,5 | 3,5 |
| | 3 | 27,5 | 6,5 | 22,5 | 3,3 |
| | 4 - 6 | 25,0 | 6,0 | 20,0 | 3,0 |
| Россия укучылары Спартакиадасының финалы | 1 | 37,5 | 7,5 | 32,5 | 3,8 |
| | 2 | 30,0 | 7,0 | 25,0 | 3,5 |
| | 3 | 27,5 | 6,5 | 22,5 | 3,3 |
| | 4 - 6 | 22,5 | 6,0 | 18,0 | 3,0 |
| Россия Федерациясе Спорт Министрлыгының бердәм календарь планына кертелгән Бөтенроссия ярышлары | 1 | 15,0 | 5,0 | 7,5 | 2,5 |
| | 2 | 12,5 | 2,5 | 6,8 | 1,3 |
| | 3 | 10,0 | 2,0 | 5,0 | 0,8 |
| Идел буе федераль округы беренчелеге | 1 | 20,0 | 5,8 | 10,0 | 2,9 |
| | 2 | 17,5 | 5,3 | 9,0 | 2,7 |
| | 3 | 15,0 | 4,8 | 7,5 | 2,4 |
| Олимпия резервы дәүләт училищесына керү | - | 25,0 | 5,0 | - | - |

6. Башка бюджетара трансфертлар түбәндәге шартларда бирелә:

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында эшләүче, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы, югары квалификацияле спортчылар әзерләгән тренерларны, шулай ук спорт инструкторларын һәм спортчыларны спорт ярышларында алган нәтиҗәләре өчен бүләкләү тәртибен үз эченә алган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары турында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының норматив хокукый акты белән расланган нигезләмә булуы;

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетында (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетының җыелма бюджет язмасы) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен кирәкле күләмдә бюджет ассигнованиеләре булу (аларны финанслау максатларында тулы күләмдә башка бюджетара трансфертлар бирелә);

әлеге Тәртипнең 11 пункты нигезендә башка бюджетара трансфертлар бирү турында Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы белән килешү төзү.

7. Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертларны бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән раслана.

8. Тиешле финанс елына (Si) Татарстан Республикасы i- муниципаль берәмлегенә башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S_i = = 1\ (O_v\ Ч_{tpj}) + (B_{vrr}\ x\ \ Ч_{cpJ}))x\ (100 + C_j)\ x\ 12,$$

биредә:

$O_v$- физик культура һәм спорт өлкәсендә программаларны гамәлгә ашыручы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы j-муниципаль физкультура спорт оешмасында югары квалификацияле спортчылар әзерләгәне өчен тренерлар оклады. Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына бюджетара трансфертлар күләмен исәпләгәндә күрсәтелгән окладлар спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары тренерларының "Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында" 2018 елның 25 сентябрендәге 853 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган хезмәт өчен түләү окладларына тигез күләмдә алына;

$Ч_{tpj}$- j-муниципаль физкультура спорт оешмасында югары квалификацияле спортчыларны әзерләүне гамәлгә ашыручы, Татарстан Республикасы i-муниципаль берәмлегендә соңгы ике финанс елында күрсәтелгән тренерларның факттагы саны турында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары мәгълүматлары нигезендә Татарстан Республикасы спорт министрлыгы тарафыннан планлаштырыла торган тренерларның еллык саны;

**Bvrr** - j- муниципаль физкультура спорт оешмасындагы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы спортчы-инструкторларга ярышларда алган урын буенча югары эш нәтиҗәләре өчен һәм рәсми бөтенроссия һәм халыкара ярышларда уңышлы чыгыш ясаганнары һәм ирешкән нәтиҗәләре өчен спортчыларга түләүләр. Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына бюджетара трансфертлар күләмен исәпләгәндә күрсәтелгән окладлар спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары спорт инструкторларының һәм спортсменнарның "Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында" 2018 елның 25 сентябрендәге 853 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган хезмәт өчен түләү окладларына тигез күләмдә алына»;

$Чср_J$ - муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары күрсәтмәләре нигезендә спортчыларның - инструкторларның һәм спортчыларның Татарстан Республикасы i-муниципаль берәмлегендә соңгы ике финанс елында факттагы саны турында Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарфыннан планлаштырылган, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы j-нче муниципаль физкультура спорт оешмасында эшләүче, ярышларда урыннар алган спортчы-инструкторларның һәм рәсми бөтенроссия һәм халыкара ярышларда уңышлы чыгыш ясаган һәм уңышларга ирешкән спортчыларның уртача еллык саны;

Cj - j-муниципаль физкультура спорт оешмасы хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча түләүләргә чыгымнар;

n - Татарстан Республикасы i муниципаль берәмлегендә спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары саны.

9. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе Министрлыкка Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетына, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы "Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесендә эшләүче, югары квалификацияле спортчылар әзерләгән тренерларны, шулай ук спорт инструкторларын һәм спортчыларны спорт ярышларында алган нәтиҗәләре өчен бүләкләүгә акча алу өчен, әлеге Тәртипкә туры китереп һәм ярышлар беркетмәсенең күчермәсе нигезендә башка бюджетара трансфертлар алуга гариза (алга таба - гариза) тапшыралар.

10. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә финанслауның иң чик күләмнәрен тиешле календарь айга (Sjm) җиткерү өчен башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S_{im} = \sum_{j}^{n} = 1 \left(\left(O_v \times Ч_{tfj}\right) + \left(B_{vrr} \times Ч_{cj}\right) + C_j\right),$$

биредә:

$O_v$ - физик культура һәм спорт өлкәсендә программаларны гамәлгә ашыручы спорт резервын әзерләүне башкаручы j-муниципаль физкультура спорт оешмасында югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен ярышларда алган урын буенча тренерлар оклады. Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына бюджетара трансфертлар күләмен исәпләгәндә күрсәтелгән окладлар спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары тренерларының "Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында" 2018 елның 25 сентябрендәге 853 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган хезмәт өчен түләү окладларына тигез күләмдә алына»;

Чtfj j-спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы j-муниципаль физкультура спорт оешмасында югары квалификацияле спортчыларны әзерләүне гамәлгә ашыручы тренерларның хисап аенда факттагы саны;

Bvrr - спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы j-муниципаль физкультура спорт оешмасында эшләүче ярышларда алган урын буенча югары эш нәтиҗәләре өчен спортчы-инструкторларга һәм рәсми халыкара, бөтенроссия, округ һәм республика ярышларында уңышлы чыгыш ясаганнары һәм ирешкән нәтиҗәләре өчен спортчыларга түләүләр. Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына бюджетара трансфертлар күләмен исәпләгәндә күрсәтелгән окладлар спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары спорт инструкторларының һәм спортчыларның "Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында" 2018 елның 25 сентябрендәге 853 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган хезмәт өчен түләү окладларына тигез күләмдә алына»;

$Ч_{cj}$ - j-нче муниципаль физкультура спорт оешмасындагы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы ярышларда урыннар алучы спортчы-инструкторлар һәм рәсми бөтенроссия һәм халыкара ярышларда уңышлы чыгыш ясаган һәм югары нәтиҗәләргә ирешкән спортчыларның факттагы саны.

Cj - j-муниципаль физкультура - спорт оешмасында эшләүчеләрнең хезмәт хакы буенча түләүләргә чыгымнар;

n - Татарстан Республикасы i муниципаль берәмлегендә спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары саны.

11. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты арасында төзелә торган башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы килешү (алга таба - килешү) нигезендә тиешле финанс елының 25 гыйнварыннан да соңга калмыйча бирелә, анда түбәндәгеләр күрсәтелгән булырга тиеш:

башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше; бирелә торган башка бюджетара трансфертларның күләме; башка бюджетара трансфертларны күчерү сроклары;

башка бюджетара трансфертларны кулланунын нәтиҗәлелеге күрсәткечләре;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

башка бюджетара трансфертлар алучының финанс белән тәэмин итү чыганагы булган башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен үтәү турында хисап тапшыру тәртибе, формасы һәм сроклары;

әлеге Тәртиптә билгеләнгән шартлар бозылган очракта килешүне өзү тәртибе;

якларның җаваплылыгы .

12. Башка бюджетара трансфертларны куллануның нәтиҗәлелеген бәяләү башка бюджетара трансфертларны куллануның нәтиҗәлелегенең (нәтиҗәләре) максатчан күрсәткечләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

13. Башка бюджетара трансфертларны куллануның максатчан күрсәткече (нәтиҗәлелеге) - Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында спорт әзерлеге узучы, спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы җыелма спорт командалары әгъзалары яки әгъзага кандидатлар булган затлар саны.

14. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетын финанслаштыру максатында, килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертларны куллануның нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләренә ирешү зарурлыгыннан чыгып, тулы күләмдә башка бюджетара трансфертлар бирелә торган бюджет ассигнованиеләре күләме, җирле бюджет турындагы карар белән раслана (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетының җыелма бюджет язмасы белән билгеләнә).

15. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы, югары квалификацияле спортчыларны әзерләүне гамәлгә ашыручы тренерлар, шулай ук ярышларда алган нәтиҗәләре булган спортчы-инструкторлар һәм спортчылар реестрын алып бара, һәм ай саен, агымдагы айның 5 числосыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына башка бюджетара трансфертлар бирү өчен реестр һәм гариза тапшыра.

16. Министрлык спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләгән югары квалификацияле спортчылар, шулай ук ярышларда алган нәтиҗәләре булган спортчы- инструкторлар һәм спортчыларның җыелма реестрын алып бара һәм ай саен, агымдагы елның 15 числосыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына башка бюджетара трансфертлар бирү өчен гариза бирә.

17. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Министрлыкның башка бюджетара трансфертлар бирү турында гаризасы килгәннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча, күрсәтелгән максатларга финанслауның иң чик күләмнәрен җиткерү өчен, Министрлыкка чыгым расписаниесен җибәрә.

18. Министрлык, әлеге максатларга финанслауның иң чик күләмнәрен җиткергән көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең Россия Банкының хисап челтәре бүлекчәләрендә ачылган исәп-хисап счетына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты акчаларын исәпкә алу өчен башка бюджетара трансфертларны күчерә.

19. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты ай саен, хисаптан соң килүче айның 15 числосыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының финанс белән тәэмин итү чыганагы башка бюджетара трансфертлар булган бюджеты чыгымнары һәм башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелек күрсәткечләрен үтәү турында хисапларны килешүдә каралган форма һәм тәртип буенча Министрлыкка тапшыралар.

20. Министрлык ай саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 20 числосыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булган бюджетларының чыгымнары һәм башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен үтәү турында хисапны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән формада Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшыра.

21. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү елының 31 декабренә әлеге Тәртипнең 13 пунктында каралган күрсәткечкә ирешмәгән очракта, муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирелгән (Vкире кайтару) елдан соң килүче елның 1 мартына кадәр кире кайтарылырга тиешле акчалар күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$V_{кире\ кайтару} = V_{мбт} \times k \times 0{,}1,$$

биредә:

Vмбт - хисап финанс елында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына бирелгән башка бюджетара трансфертлар күләме;

k - башка бюджетара трансфертларны кире кайтару коэффициенты.

22. Татарстан Республикасы бюджетына хисап финанс елында(Vмбт) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына бирелгән башка бюджетара трансфертлар күләмендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акчалар күләмен исәпләгәндә башка бюджетара трансфертлар бирү елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларның калган күләме исәпкә алынмый.

23. Башка бюджетара трансфертларны кире кайтару коэффициенты ( ^ ) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$k = 1 - T / S$$

биредә:

T- ел ахырына башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең фактта ирешелгән күрсәткече;

S - килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертларны куллану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең пландагы күрсәткече.

24. Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары бозылган очракта, шул исәптән Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы тарафыннан әлеге Тәртипнең 23 пункты нигезендә Татарстан Республикасы

бюджетына акча кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган мәҗбүр итү чаралары кулланыла.

25. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына кулланылмаган башка бюджетара трансфертлар акчалары агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне дәвамында Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмаган калдыгы Татарстан Республикасы бюджеты керемена күчерелмәгән очракта, күрсәтелгән акчалар, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә, Татарстан Республикасы бюджеты керемена алынырга тиеш.

Министрлыкның хисап финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турындагы карар нигезендә, күрсәтелгән башка бюджетара трансфертларның калдыкларыннан артмаган күләмдә акчалар моңа кадәр бирелгән муниципаль берәмлек бюджеты керемена агымдагы финанс елында күрсәтелгән башка бюджетара трансфертларны бирү максатларына туры килә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү өчен кире кайтарылырга мөмкин.

26. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты, тапшырыла торган хисап белешмәләренең дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмау өчен законнар нигезендә җавап тота.

27. Башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын контрольдә тоту закончалыклар нигезендә Татарстан Республикасы спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.